КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 17 апрель г.Казань № 479

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Акционерлык җәмгыятьләренең идарә һәм тикшерү органнарында дәүләт мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү турында» 2021 ел, 2 апрель, 210 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Акционерлык җәмгыятьләренең идарә һәм тикшерү органнарында дәүләт мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү турында» 2021 ел, 2 апрель, 210 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның дүртенче, бишенче, алтынчы абзацларында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Директорлар советларына (күзәтү советларына) һәм ревизия комиссияләренә дәүләт вәкилләре Татарстан Республикасы Президенты белән килештергәннән соң махсус хокук («алтын акция») нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган акционерлык җәмгыятьләре исемлегенең исемендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Акцияләренең дәүләт пакетлары «Связьинвестнефтехим» ачык акционерлык җәмгыяте устав капиталына кертелгән, директорлар советларына (күзәтү советларына) һәм ревизия комиссияләренә дәүләттән кандидатуралар Татарстан Республикасы Президенты белән килештергәннән соң «Связьинвестнефтехим» ачык акционерлык җәмгыятенең вәкаләтле органнары тарафыннан тәкъдим ителә торган акционерлык җәмгыятьләре исемлегендә:

исемендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:

«12. «КАМАЗ» гавами акционерлык җәмгыяте.»;

әлеге карар белән расланган Акцияләренең дәүләт пакетлары «Ак Барс» холдинг компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте устав капиталына кертелгән, директорлар советларына (күзәтү советларына) һәм ревизия комиссияләренә дәүләттән кандидатуралар Татарстан Республикасы Президенты белән килештер-гәннән соң «Ак Барс» холдинг компаниясе» ачык акционерлык җәмгыятенең вәкаләтле органнары тарафыннан тәкъдим ителә торган акционерлык җәмгыятьләре исемлегенең исемендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин